
# Мулла килене

(повесть)

“...**XX** гасырның утызынчы-кырыгынчы еллары илебез тарихына тетрәндергеч репрессияләр,халыкның иң яхшы улларын һәм кызларын юк итү чоры булып кереп калган. Роза Хәбибуллина “Мулла килене” әсәрендә әнә шул коточкыч фаҗиганең аерым кешеләр язмышында уйнаган ролен сурәтли.Әсәр ил тормышының җитмеш ел чамасы дәверен колачлый. Анда репрессия заманнары, сугыш елларының ачы газабы, тылда калган хатын-кызлар, балалар һәм үсмерләрнең авыр тормышы,тырыш хезмәте бәян ителә. Повесть сюжеты, шул чорлар аша урап, бүгенге көннәргә кадәр килеп җитә”
Фоат Садриев



Туган җирләреннән сөрсәләр дә, кешенең күңеленә берәү дә богау сала алмый. Баш очларында кыргый урман шаулаганда, Миргаяз хәзрәт киләчәк турында уйлады, тормышларын планлаштырды. Ходайның адәм затына биргән иң зур нигъмәте- акыл. Миргаяз бу дөньяда күп яшәде, күпне күрде, бик авыр чакларда да чыгу юлын тапты.






Маһинур бу очрашуның язмыш икәненә ышанды. Кичә генә Ижау егете кыз күзләргә килүен ишеткәч, йөзе кына чәчкәсе кебек кабынып китте, күзләре очкынланды, йөрәге кош канатыдай талпынды! Гомергә күрмәгән егетнең  башка бер кызга каравыннан курыкты, үзенә булуын теләде. Моңа кадәр бер егетне дә якын җибәрмәгән кызның күңеле менә кемне көткә икән!



Вокзал тулы халык: елыйлар, шаулыйлар, җырлыйлар- бииләр, бу тавыштан, бигрәк тә җырлау-биюдән Маһинур гаҗиз- аның иренә сыенып, аны гына ишетеп торасы килә.

- Маһинурым, мин сиңа хатларны гел язып торырмын. Син минем дөньядагы иң зур бәхетем! Мин сине өзелеп яратам! Мине көт! Үлгән дигән хәбәр килсә дә, тагын бер ел көт!





Сугыш башланганнан бирле туя ашамаган колхозчыларның ихатасына мондый ашлык кайтканы юк иде. Көнкүрмеш халкы бу бәхеткә ышанып бетә алмый... Маһинурның гына җаны тыныч түгел. Уңышны яшергәнне белсәләр, туп-туры төрмәгә ябачаклар, Аллам сакласын! Авыл халкы әләкләшеп йөрмәс йөрүен, менә Көтер генә...





Күпме еллар көтеп алган бәхетеннән Маһинурның холкы да үзгәрде: ул хәзер сабыррак, кешеләргә игътибарлырак, мәрхәмәтлерәк. Бу үзгәрешне авыл халкы колхоз рәисе булып күтәрелүгә юрады.



Маһинур мулла килене булуны олы дәрәҗәгә саный, абруйлылык, чисталык, пакьлек дип аңлый. Моның чыны да шулай. Гади авыл кызы Миргаяз хәзрәт гаиләсендә зур тәрбия, белем, гыйлем алды. Бу сүзнең хикмәте бар- авылдашларына тылсым кебек тәэсир итә: Маһинурның мулла гаиләсендә яшәве саваплы изгелек кебек тоела, шуның өчен аңа авыр сүз әйтүче, гайбәт җиткерүче булмады, сөйләсәләр сөйләгәннәрдер



Маһинур сиксән җидесен тутырып, сиксән сигезенчегә чыкты.Үз өлешенә тигән гомереннән канәгать: язмыш аңа шатлыкларны да, кайгыларны да мулдан бирде. Дөнья дигән иксез-чиксез тормышының баллы да, әче дә җимешләрен татыды. Сизгер күңел күзе кечкенә сөенечләрдән дә тәм табарга, куанырга өйрәтте. Инде китәргә дә вакыт җитә...



Күптән түгел тормыш кайнап, гөрләп торган авыл тынып калды: башта балалар укырга, һөнәр алырга дип чыгып киттеләр дә кайсы кайда төпләнеп калдылар, туган авылларына кире кайтмадылар; колхоз беткәч, яшь гаиләләр кузгалдылар; Көнкүрмештә өлкәннәр генә утырып калды...



“Безнең авылга кызыгучылар күп. Белмәссең, асфальтны авылга кадәр җәйсәләр, күчеп килүчеләр күбәер, ихтимал, яшьләр дә килер, үзебезнең авылдашлар да кайтыр”,- дип уйлады Ирек.

Оныгы Булат үсә төшкәч, монда алып килер, үзе уйнап үскән Кушчишмә тавына да, аккошлар килә торган йомры күлгә дә алып барыр... Оныгын күз алдына китереп елмайды, күңелен шатлык хисе биләде...

